**7нче билет**

| Биремнәр | Җаваплар |
|---|---|
| **1. Текстны укыгыз, эчтәлеген сөйләгез.**<br>**Нинди һөнәр сайларга?**<br>Безнең сыйныфта 23 укучы укый. “Нинди һөнәр сайларга?” дигән кичә үткәрдек. Кичәгә әтиләр һәм әниләр килде, һәм алар үзләренең һөнәрләре турында сөйләделәр.<br>Валяның әнисе ашханәдә официант булып эшли. Бу ашханәдә татар халкының милли ашларын бик тәмле пешерәләр икән. Әтисе елга портында эшли, ул – капитан.<br>Костяның әнисе балалар бакчасында тәрбияче булып эшли. Әтисе – спортчы.<br>Раяның әнисе генә бар. Ул институтта химия фәнен укыта.<br>Безгә әтиләр, әниләр үз һөнәрләре турында сөйләделәр. Һөнәрне сайлау бик җаваплы, бик әһәмиятле икән.<br>Ф.С. Сафиуллинадан | 1**. Прочитайте и перескажите содержание текста.** |
| **2. Әйтик сез эшкә керергә килдегез. Сезнең белән эшкә алучы арасында нинди сөйләшү булыр? Эш урыннары (үзегез сайлап алыгыз): мәктәп, банк, завод, ресторан.** | **2.Допустим, что вы пришли устраиваться на работу в банк (школу, завод, ресторан) Какой диалог состоится между вами?**<br>-Исәнмесез, Анатолий Викторович! Керергә мөмкинме?<br>- Хәерле иртә! Керегез! Бирегә утырыгыз.<br>- Рәхмәт! Мин – Юрий Юрьевич. Сезнең кадет мәктәбендә тарих укытучысы булып эшлисем килә.<br>- Тарих укытучысы безгә бик тә кирәк! Белемегез нинди?<br>- Мин – АДПУ да тарих бүлеген бетердем, менә минем дипломым.<br>- Яхшы. Сәркәтипкә кереп кирәкле документларны тутырыгыз һәм иртәгә сәгать сигезгә эшкә килегез.<br>- Рәхмәт сезгә. Сау булыгыз!<br>- Сау булыгыз! |
| **3. Тезмә фигыльләрне тәрҗемә итегез, 3-4 сорау җөмлә төзегез.**<br>Йөгереп килә, китеп бара, <u>алып кайта, алып килә</u>, җавап бирә, сорау бирә, очып керә. | **3.Переведите составные глаголы, составьте с ними 3-4 вопросительных предложения.**<br>Прибегает, уходит, <u>приносит, приносит</u>, отвечает, спрашивает, влетает.<br>Ул өенә гел бишлеләр алып кайта. Дәрестә игътибарлы кадет дөрес җавап бирә. Костя шатлыгыннан сыйныфка очып керә. |
| **4. Үзегезгә ошаган шигырьне яттан сөйләгез.** | **4.Расскажите своё любимое стихотворение.**<br>Әни кирәк |

| | |
|---|---|
| | Көннәр якты булсын өчен,<br>Йокы татлы булсын өчен,<br>Әни кирәк, әни кирәк.<br>Йокы татлы булсын өчен,<br>Әни кирәк. Әни кирәк.<br>Җил-яңгырдан саклар өчен,<br>Усаллардан яклар өчен<br>Әни кирәк.<br>Ашлар тәмле былсын өчен,<br>Дөнья ямьле булсын өчен<br>Гөлләр чәчәк атсын өчен,<br>Бәхет-шатлык артсын өчен,<br>Әни кирәк, әни кирәк.<br>Иң кадерле кеше җирдә –<br>Әни димәк.<br>Р. Миңнуллин |
| **5. Тәрҗемә итегез:**<br>1) Бакчадан саф һава керсен өчен, тәрәзәләрне ачыгыз.<br>2) Чәчәкләр сулмасын өчен,кич белән су сибәргә кирәк.<br>3) Мы составили план для того, чтобы садовник правильно расположил грядки.<br>4) У бордюров посадили цветы, чтобы было красиво. | **5.Переведите.**<br>1. Откройте окно, чтобы проветрить комнату.<br>2. Вечером нужно поливать цветы, чтобы они не завяли.<br>3. Бакчачы түтәлләрне дөрес ясар өчен, без план төзедек.<br>4. Матур булсын өчен, бордюр янына чәчәкләр утырттык. |